| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2025 г. Казань № 654-155/тэ-2025

«Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан Казан шәһәре кулланучыларына, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 12.11.2025 ел, №267-23/тэ-2025 карары белән билгеләнгән тарифларга 2026 ел өчен төзәтмә кертү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 12.11.2025 ел, №267-23/тэ-2025 карарына 2 нче кушымтага үзгәреш кертү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 18.12.2025 ел, №34-ПР беркетмәсе нигезендә һәм 2026 елга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп һәм озак сроклы җайга салу параметрын яңадан карап, 2026 елга җылылык энергиясенә тарифларны төзәтү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан Казан шәһәре кулланучыларына, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан Казан шәһәре кулланучыларына, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә 2024-2028 елларга тарифлар билгеләү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2023 ел, №724-80/тэ-

2023 һәм 20.12.2024 ел, №730-117/тэ-2024 карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 12.11.2025 ел, №267-23/тэ-2025 карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 12.11.2025 ел, №274-30/тэ-2025 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән билгеләнгән тарифларга 2026 ел өчен төзәтмә кертеп, 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (кушымтада) бирергә.

2. Әлеге карарның 1 пункты белән төзәтелгән тарифлар 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан Казан шәһәре кулланучыларына, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә 2024-2028 елларга тарифлар билгеләү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2023 ел, №724-80/тэ-2023 һәм 20.12.2024 ел, №730-117/тэ-2024 карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 12.11.2025 ел, №267-23/тэ-2025 карарына 2 нче кушымтага үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
12.11.2025 ел, № 267-23/тэ-2025
карарына 1 кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2025 № 654-155/тэ-2025
карары редакциясендә)

## «Татэнерго» АҖ тарафыннан Казан шәһәрендәге кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга бирелә торган җылылык энергиясенә 2024-2028 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | Басым астында сайланма пар | | | | Кискен һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| 1 | «Татэнерго» АҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 1.1.1 | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 30 июненә кадәр | 1 780,50 | - | - | - | - | - |
| | | 2024 елның 1 июленнән 2024 елның 31 декабренә кадәр | 1 972,79 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 1 972,79 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 2 412,70 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 2 412,70 | - | - | - | - | - |
| | | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 2 801,14 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2027 башлап | 2 786,44 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 30.06.2027 кадәр | | | | | | |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 3 045,58 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 3 045,58 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 3 252,68 | - | - | - | - | - |
| | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән) <*> | | | | | | | |
| 1.1.2 | бер ставкалы, сум/Гкал | 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 30 июненә кадәр | 2 136,60 | - | - | - | - | - |
| | | 2024 елның 1 июленнән 2024 елның 31 декабренә кадәр | 2 367,35 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 2 367,35 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 2 895,24 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 2 943,49 | - | - | - | - | - |
| | | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 3 417,39 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 3 399,46 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 3 715,61 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 3 715,61 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 3 968,27 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
12.11.2025 ел, № 267-23/тэ-2025
карарына 2 кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2025 № 654-155/тэ-2025 карары
редакциясендә)

# Билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып тарифлар формалаштыру өчен 2024-2028 елларга җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган озак сроклы җайга салу параметрлары

| Т/с | Җайга салынулы оешманың исеме | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнары-ның нәтиҗәлелек индексы | Норматив табыш дәрәҗәсе | Җылылык белән тәэмин итүнең ышанычлылык дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | | Ягулык чыгымна-рын үзгәртү динами-касы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | мең сум | % | % | Җылылык челтәрләрендә 1 км җылылык челтәрләренә технологик җитешсезлекләр нәтиҗәсендә җылылык энергиясе бирүне туктатулар саны | Җылылык энергиясенең технологик сарыфлары зурлыгының җылылык челтәренең матди сыйфатламасына карата нисбәте | Җылылык энергиясен тапшырганда технологик югалту зурлыклары, Гкал | |
| 1 | «Татэнерго» АҖ | | | | | | | | |
| 1.1 | Казан шәһәре | 2024 | 1 002 464,79 | - | - | 0,19 | 1,82 | 634 421 | - |
| | | 2025 | - | - | - | 0,19 | 1,82 | 634 421 | - |

| Т/с | Җайга салынулы оешманың исеме | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнары-ның нәтиҗәлелек индексы | Норматив табыш дәрәҗәсе | Җылылык белән тәэмин итүнең ышанычлылык дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | | Ягулык чыгымна-рын үзгәртү динами-касы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | мең сум | % | % | Җылылык челтәрләрендә 1 км җылылык челтәрләренә технологик җитешсезлекләр нәтиҗәсендә җылылык энергиясе бирүне туктатулар саны | Җылылык энергиясенең технологик сарыфлары зурлыгының җылылык челтәренең матди сыйфатламасына карата нисбәте | Җылылык энергиясен тапшырганда технологик югалту зурлыклары, Гкал | |
| | | 2026 | 1 438 177,39 <*> | - | - | 0,19 | 1,82 | 634 421 | - |
| | | 2027 | - | 1 | - | 0,19 | 1,82 | 634 421 | - |
| | | 2028 | - | 1 | - | 0,19 | 1,82 | 634 421 | - |

<*> Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары белән расланган Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү нигезләренең 51 пункты нигезендә яңадан каралган

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге